ГЛАВА КОРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная площадь, д.1, с. Коргуза, 422586

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАРАГУЖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 1 нче йорт, Карагужа авылы, 422586

Тел.: (84379) 35-5-70, факс: (84379) 35-5-70.

16.12.2025 № 02

На №______________ от________________

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлегенең Карагуҗа авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының

- Карагуҗа торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

(- җирлек ихтыяҗларын тәэмин итүче исәбеннән товарны билгеләнгән пунктка алтеп җиткереп, Карагуҗа авылында юлларны ремонтлау өчен асфальт грануляты һәм вак таш сатып алу) дигән мәсьәлә буенча 2025 елның 16 декабрендә узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының уздырылган этаплары нәтиҗәләре буенча җыенның йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 342 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 177 кеше кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 177 катнашучы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегенең Карагуҗа авылында халык җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлегенең Карагуҗа авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда үзара

салымны 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы сез?:

- Карагуҗа торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

(- җирлек ихтыяҗларын тәэмин итүче исәбеннән товарны билгеләнгән пунктка илтеп җиткереп, Карагуҗа авылында юлларны ремонтлау өчен асфальт грануляты һәм вак таш сатып алу) дигән мәсьәлә буенча карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегенең Карагуҗа авылындагы гражданнар җыены нәтиҗәләрен Карагуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Д.В.Плохов